Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.05.2025 Менделеевск ш. № 352

Хуҗасыз хйваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьясы нигезендә, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Хуҗасыз хйваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Карар билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында басылып чыгарга тиеш (http://pravo.tatarstan.ru ), Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга (http://mendeleevsk.tatarstan.ru ).

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С. В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 22 маендагы 352 номерлы
карарына 1 кушымта

Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеге

- Гомуми файдаланудагы территорияләр (шул исәптән мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, скверлар һәм чикләнмәгән затлар тоткарлыксыз файдалана торган башка территорияләр);
- күпфатирлы йортлар янындагы территорияләр;
- балалар өчен уен һәм балалар өчен спорт мәйданчыклары;
- актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;
- массакүләм чаралар уздыру мәйданчыклары;
- балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
- мәдәният объектларына якын территорияләр;
- җәмәгать тукланучы оешмалары, кибетләр янындагы территорияләр.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 22 маендагы 352 номерлы
карарына 2 кушымта

Хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары